КАРАР

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге составына керүче Свердловец торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның 27 ноябре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 27 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Кармалы авыл җирлеге Свердловец торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире 600 сум күләмендә 2025 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Әлеге сумманың 50% күләмендә 2 группа инвалидлар, 80 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнар, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баланың ата-аналары түли. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Свердловец бистәсенең Ленин урамындагы бетон юлны ремонтлау).

ӘЙЕ ЮК».

Мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 149 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 81 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 81 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге составына керүче Свердловец торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип таныргга.

2. «Түбән Кама муниципаль районының Кармалы авыл җирлеге Свердловец торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге укү формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире 600 сум күләмендә 2025 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Әлеге сумманың 50% күләмендә 2 группа инвалидлар, 80 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнар, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баланың ата-аналары түли. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Свердловец бистәсенең Ленин урамындагы бетон юлны ремонтлау).

ӘЙЕ ЮК»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Кармалы авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кармалы авыл җирлеге башлыгы А.Д. Кубышкин